РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.07.2024 № 577-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 09 октябрендәге 1280-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә балаларны карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы нигезендә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 09 октябрендәге 1280-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә балаларны карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «7. Мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрне карап торган һәм караган өчен ата-ана түләве өлкән бала 18 яшькә җиткәнчегә кадәр күпбалалы гаилә өчен яисә 23 яшькә җиткәнчегә кадәр, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге бүлектә белем алу шартларында 50 процентка кими.»;

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

Җитәкче М. Р. Ишниязов